Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Ислəй авыл җирлеге Советы
Карары

№5/2 2020 елның 30 декабре

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге милкендəге муниципаль мөлкəт исемлеген кече һəм урта эшкуарлык субъектларына билəүгə һəм (яисə) файдалануга тапшыру өчен билгелəнгəн муниципаль мөлкəт исемлеген булдыру, алып бару һəм бастырып чыгару тəртибен раслау турында» 2019 елның 5 июнендəге 62/2 номерлы карарына үзгəрешлəр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чистай шəһəр прокуратурасының 2020 елның 11 декабрендəге 02-08-02-2020 номерлы протестын карап чыканнан соң, «Россия Федерациясендə кече һəм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законы һəм «Россия Федерациясендə кече һəм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законына үзгəрешлəр кертү хакында» Федераль законның 1 һəм 2 статьяларына үзгəрешлəр кертү турында» 2020 елның 08 июнендəге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендə, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге милкендəге муниципаль мөлкəт исемлеген булдыру, алып бару һəм бастырып чыгару тəртибен раслау турында» 2019 елның 05 июнендəге 62/2 номерлы карарына кече һəм урта эшкуарлык субъектларына билəүгə һəм (яисə) файдалануга тапшыру өчен билгелəнгəн түбəндəге үзгəрешлəрне һəм өстəмəлəрне кертергə:

исемендə «кече һəм урта эшкуарлык субъектларына» сүзлəреннəн соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һəм махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзлəрен өстəргə;

1 пунктта:

«кече һəм урта эшкуарлык субъектларына ярдəм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзлəреннəн соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һəм махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзлəрен өстəргə;

Карарның 1 нче кушымтасында:

исемендə, 1.1, 1.4, 2.4 пунктларында «кече һəм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзлəреннəн соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һəм махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзлəрен өстəргə.

3. Әлеге карарны авыл җирлегендə яшəүчелəрне күплəп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һəм такталарында элү юлы белəн игълан итəргə, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рəсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) «Интернет» мəгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Исләй авыл җирлеге
башлыгы В.П.Чернышев